# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**(III чакырылыш)**

киңәйтелгән егерме алтынчы утырыш

## КАРАРЫ

14 февраль 2019 ел **№ 164** Теләче авылы

Теләче муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисади үсеш йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында

Теләче муниципаль районы Башлыгы И. Ф. Зариповның «Теләче муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында»гы хисабын тыңлап, фикер алышканнан соң, Теләче муниципаль районы Советы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131 санлы Федераль закон йөкләгән вәкаләтләрне һәм 2004 елның 28 июлендәге 45 санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законын тормышка ашыруга юнәлдерелүен билгеләп үтә. Теләче муниципаль районы Уставына туры китереп, район халкының тормыш дәрәҗәсе сыйфатын күтәрү һәм районның максатчан социаль-икътисади үсешен тәэмин итү максатыннан, Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1.Теләче муниципаль районы Башлыгы И. Ф. Зариповның «Теләче муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында»гы хисабын исәпкә алырга.

**1.Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына, бюджетта билгеләнгәннәрне үтәү һәм социаль инфраструктураның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү максатыннан, 2019 елга түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- «Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеше стратегиясе» кысаларында, халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга, сәнәгать продукциясен җитештерү күләмен һәм сатуны арттыруга барлык көчне юнәлтеп, Теләче муниципаль районының 2030 елга кадәр үсеш стратегиясен тормышка ашыру буенча эш оештырырга;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән Теләче муниципаль районы арасында планлаштырыла торган күрсәткечләргә ирешү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторы турында төзелгән килешүне үтәү буенча конкрет чаралар күрергә. Агымдагы елда индикатив

күрсәткечләргә ирешүнең комплекслы планын эшләп, расларга һәм аның үтәлешен вакытында күзәтеп барырга;

- ведомствоара эшчәнлек кысаларында, район территориясендә керемнәрне легальләштерү буенча чаралар үтәлешен тәэмин итәргә, хезмәт хакы түләү буенча бурычлар барлыкка килүенә юл куймаска;

- аерым категория гражланнарны торак белән тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыруны контрольгә алырга, 2019 елга планлаштырылган торакны 100% эксплуатациягә тапшыруны тәэмин итәргә;

- күпкатлы йортларга капиталь ремонт үткәрелүгә бүленгән акчаларны вакытында һәм максатчан кулланыну тәэмин итәргә, башкарылучы эшләрнең сыйфатына җәмәгать контроле булдырырга;

- ветераннар, өлкән яшьтәге гражданнар белән эшне активлаштырырга, аларның актив катнашында чаралар оештырырга. Ветераннар Советы һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты арасында үзара ярдәмләшеп эшләү турында килешү әзерләргә һәм расларга;

- хуҗалык эшчәнлегенең төрле тармакларында, шул исәптән авыл хуҗалыгы производствосында, мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне кертү буенча планлы эш алып барырга;

- 2019 елның 8 сентябрендә узачак Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары сайлауга әзерләнүдә һәм үткәрүдә район сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтергә;

- Татарстан Республикасының Теләче муниципаль районы территориясендә сәгатенә 6 тонна җитештерүчәнлеге булган табигый газны сыекландыру комплексы (КСПГ-6) төзелешенә, гамәлдәге законнар кысаларында, булышлык итәргә;

- энергияне саклау буенча программа чараларын тормышка ашырырыга;

- район халкына торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту буенча нәтиҗәле чаралар күрергә;

- хокук саклау органнары белән берлектә, терроризмны, экстремистлык эшчәнлекне кисәтү һәм радикаль идеология карашларына чик кую буенча эшнең нәтиҗәлелеген арттырырга;

- традицион конфессияләр арасында диалог алып баруга һәм үзара аңлашуга, милләтара килешүгә булышлык итәргә;

- яшьләрне рухи һәм физик тәрбияләүгә, толерантлыкка, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә ярдәм итүгә, булган спорт базаларын нәтиҗәле файдалану хисабына массакүләм спортны үстерүгә шартлар тудыруга, район халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

- коррупциягә каршы тору, хокук бозуларны профилактикалау буенча программа чараларын үтәргә;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итү буенча дәүләт программаларында максималь катнашырга. Эшмәкәрләр җитештергән продукцияне сату системасын булдыруга булышлык итәргә;

- райондагы гаилә фермалары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү, аларны үстерү буенча программа чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

- сыйфатлы һәм үз вакытында муниципаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итәргә;

- «Театр елы» кысаларында районның чаралар планын эшләргә һәм расларга, аның үтәлешен тәэмин итәргә;

- гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны муниципаль заказ бирүчеләр белән тәэмин итәргә;

- 2019 елның 1 маена кадәр авылда хуҗалык итүнең кече формаларын җәелдерү буенча программа эшләргә һәм кабул итәргә, һәм квартал саен мониторинг үткәреп, мәгълүматны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына тапшырырга;

- Теләче авылында спорт кластерын гамәлгә ашыру буенча юл картасы эшләргә;

- ТАССР төзелүгә 100 тулуны бәйрәм итүгә әзерләнүнең муниципаль һәм ведомство планнарын үтәү буенча чаралар күрергә;

- 2019 елның 1 яртыеллыгы дәвамында район халкына аналог телевидение тапшыруларының цифрлы тапшыруга күчүе турында аңлату эшләре алып баруны оештырырга;

- беренче кварталда каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча халыкка хезмәт күрсәтүдә региональ операторлар белән үзара килешеп эшләүне оештырырга;

- халыкка электрон дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә игътибарны арттырырга.

**2.1. Теләче муниципаль районы территориясендә компетентлылык кысаларында сәнәгать паркларын үстерү буенча:**

- инвестицион климатны яхшырту, сәнәгать паркына, тулаем алганда районга, инвесторлар җәлеп итү буенча планлы эшне дәвам итәргә;
- сәнәгать паркының фәнни үзәкләр белән үзара бәйләнешенә аерым игътибар итәргә кирәк;
- 2019 елның 30 апреленә кадәр сәнәгать мәйданнары резидентлары өчен муниципаль ташламалар бирү тәртибен яңартырга кирәк;
- кирәк очракта аккредитация процедурасы үтүдә булышлык күрсәтергә;

**3.Теләче муниципаль районы Контроль-хисап палатасына вәкаләтләре кысаларында:**

- муниципаль берәмлек бюджетының үтәлешенә контрольне тәэмин итәргә;
- Теләче муниципаль районы бюджеты акчаларының, шулай ук Теләче муниципаль районы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән каралган башка чыганаклардан кергән акчаларның законлы, нәтиҗәле (файдалы, сак) файдалануына контроль булдырырга;
- бюджет процессына аналаиз үткәрергә, кирәк очракта, аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләргә;
- файдаланылмый торган/хуҗалык әйләнешенә кертелмәгән муниципаль милек объектларына, аларны тотуга булган файдасыз чыгымнарны кыскартуга/юл куймауга юнәлдерелгән чаралар кабул итү максатыннан, ревизия үткәрүне тәэмин итәргә (ярты елга 1 тапкыр).

**4. «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә 2019 елга түбәндәге бурычлар йөкләргә:**

- барлык этапларда да белем бирү сыйфатын яхшырту, сәләтле балалар белән эшләү буенча башланган эшне дәвам итәргә, методик хезмәтнең планлы эшен оештырырга;
- республикада Эшче һөнәрләр елы кысаларында чаралар оештырырга;
- тирән анализ нигезендә муниципаль белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, база мәктәпләре булдыру һәм сыйфатлы белем бирү өчен тигез мөмкинлекләр тудыру буенча чараларны дәвам итәргә;
- муниципаль белем бирү оешмаларының нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү һәм эш методларын камилләштерү, укытуның югары технологик программаларын кертү (белем бирү системасында цифрлы грамоталылык), федераль белем бирү стандартларын үтәү буенча эзлекле процессны дәвам итәргә;
- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча программа чараларын үтәү;
- балаларны һәм яшүсмерләрне патриотик тәрбияләү буенча планлы эш оештыру;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә чиратларны киметү буенча эш алып бару.

**5. Теләче муниципаль районы финанс-бюджет палатасына 2019 елга түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- тормыш дәрәҗәсен күтәрү, керемнәрне легальләштерү һәм җирле бюджетка салымнар түләүгә контрольлек итү буенча ведомствоара комиссия белән берлектә физик затлардан, төрле милек формасындагы предприятиеләрдән. оешмалардан, учреждениеләрдән салым түләүләре һәм җыемнарның район бюджетына вакытында керүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә;
- финанс тотрыклылыгын ныгыту буенча эшне дәвам итәргә. Авыл җирлекләре башлыклары белән бергә, салым базасына анализ ясап, ял керемнәрен максималь киметергә;
- эчке финанс контролен вакытында алып баруны тәэмин итәргә.

**6. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 санлы районара инспекциясенә тәкъдим итәргә:**

- Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән берлектә 2018 елның 27 ноябрендә кабул ителгән 422 санлы «Федераль әһәмияттәге Мәскәү шәһәрендә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында (Татарстан) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кертү буенча эксперимент үткәрү турында»гы Федераль законны халыкка аңлату буенча эш алып барырга.

**7. Теләче муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2019 елга түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- муниципаль милек һәм җир участоклары белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү хисабына бюджетка керемнәр кертү буенча 2019 елга бюджет йөкләмәсен үтәүне тәэмин итәргә;
- алынмаган җир участокларын рәсмиләштерү буенча чаралар күрергә;

- милекчеләр һәм арендаторлар тарафыннан җир участокларыннан нәтиҗәле һәм максатчан файдалануга һәм алардан файдаланган өчен вакытында түләүгә контроль булдыруны тәэмин итәргә;

- күчемсез милекнең хуҗасыз объектларына инвентаризация үткәрү һәм, гамәлдәге законнар нигезендә, аларны исәпкә алу буенча эш оештырырга;

- җирләрне максатка туры килмәгән/законсыз файдалануны, шул исәптән киң таралган файдалы казылмалар чыгару буенча санкцияләнмәгән карьерлар эшкәртү, каты көнкүреш калдыклары чүплекләрен ачыклау максатыннан, территорияләрне тикшерү (шул исәптән спутник ярдәмендә/аэро-фото визуализация юлы белән, вәкаләтле органнар белән берлектә) уздыруны оештырырга;

- китерелгән зыянны бетерү, туфракның уңдырышлы катламын (авыл хуҗалыгы җирләрендә) торгызу, гамәлдәге законнар белән каралган очракта, гаеплеләрне административ һәм башка төрле җаваплылыкка тарту буенча таләпләр куярга.

**8. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә 2019 елга түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

8. 1. Яшьләр сәясәте һәм туризм өлкәсендә:

- «Эшче һөнәрләр елы»н үткәрү кысаларында чараларның район планын эшләп расларга һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә;

- яшьләрнең эш активлыгын һәм хокукый культурасын күтәрү өчен шартлар тудырырга;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны дәвам итәргә;

- патриотик тәрбия һәм экстремизмны профилактикалау буенча программа чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

- районда авыл туризмын җәелдерү буенча чаралар планын эшләп расларга;

- Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, яшьләр белән эшләүнең яңа алымнарын кертергә;

-эшче яшьләр белән эшне активлаштырырга;

- яшьләр арасында иҗади активлыкны үстерү, җәмәгать киңлекләре мәйданнарында - паркларда ялларын оештыру (популярлыгын күтәрү) буенча эш оештырырга;

8.2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә:

- район халкын сәламәт яшәү рәвеше алып баруга һәм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә тарту өчен шартлар тудырырга;

- системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның санын арттыру буенча чаралар күрергә;

- спорт-сәламәтләндерү комплексын булдыру буенча эшне дәвам итәргә;

- универсал спорт мәйданчыкларын нәтиҗәле файдалануны тәэмин итәргә;

- 2019 елның 1 маена кадәр спортның су төрләрен җәелдерү планын эшләргә;

**9. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә 2019 елга мәдәният өлкәсендә түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрергә һәм төрле мәдәни чараларда катнашучы халык санын арттырырга;

- мәдәният учреждениеләрен янгынга каршы сигнализация белән җиһазлау буенча чаралар күрергә һәм янгын куркынычсызлыгы чаралары белә тәэмин итәргә;

- Теләче муниципаль районында мәдәният һәм сәнгатьне комплексы үстерүнең программа чараларын үтәргә;

- районда милләтара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең мониторингы буенча эш алып барырга;

- районның үзәкләштерелгән китапханәләр челтәрендә һәм крайны өйрәнү музейларында эшнең яңа формаларын кертергә;

- иҗтимагый киңлекләр мәйданнарында-паркларда халыкның мәдәни активлыгын үстерү буенча эш оештырырга;

- 2019 елның 1 апреленә кадәр җирле тарихи әһәмияткә ия объектларны ачыклау буенча мониторинг үткәререгә.

**10. Россия ЭЭМның Теләче районы буенча бүлекчәсенә, компетенцияләре кысаларында, законлылык һәм хокук тәртибе өлкәсендә 2019 елга түбәндәге бурычларны билгеләргә:**

- җәмәгать урыннарында, район составына кергән авыл җирлекләре территорияләрендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтүгә аерым игътибар биреп, законлылык һәм хокук тәртибен алга таба ныгытуны тәэмин итәргә;

- район территориясендә җинаятьләр һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм киметү буенча конкрет чаралар күрергә;

- экстремизм һәм терроризмны, коррупцион хокук бозуларны профилактикалау буенча чараларны үтәү эшен көчәйтергә;

- федераль законнар нигезендә, муниципаль органнарны, гражданнарны массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет мәгълүмат-телекоммуникацион челтәре аша, шулай ук вазифаи затларның муниципаль берәмлекләрнең вәкиллек органнары һәм гражданнар алдында хисап тоту юлы белән, үз эшчәнлекләре турында даими рәвештә (елга бер тапкырдан да ким түгел) таныштырып барырга;

- ирекле халык дружиналары эшчәнлегендә методик ярдәм күрсәтергә.

**11. Теләче муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә 2019 елда түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- 2019 елда ит һәм сөт җитештерү, мөгезле эре терлекнең баш санын арттыру буенча план күрсәткечләрен үтәү өчен конкрет чаралар күрергә;

- туфракның уңдырышлылыгын күтәрү һәм тирә-як мохитне саклау буенча чаралар комплексы, авыл хуҗалыгы культуралары игүнең, авыруларга һәм корткычларга каршы тора торган яңа интенсив, ресурсларны саклаучы технологияләрне, югары уңыш бирә торган сортларны, орлыкчылыкның һәм сортларны сынауның, чәчүлек материаллары булдыру һәм сатуның нәтиҗәле системасын кертү буенча эш оештырырга;

- барлык тармакларны да комплекслы механикалаштыру нигезендә авыл хуҗалыгы производствосында инновацион технологияләр куллану, яңа техника һәм ресурсларны саклый торган технологияләр, җитештерү һәм башка объектларны төзүдә прогрессив һәм отышлы технологияләр кертү буенча чаралар оештырырга;

- районда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне, аның файдасын һәм конкуренциягә каршы торучанлыгын арттыруга, чимал һәм азык-төлекнең сыйфатын тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар күрергә;

- районда эшмәкәрлекне үстерүгә булышлык итәргә;

- агросәнәгать сферасында эшләүче җитәкчеләр һәм белгечләр, фермерлар, эшмәкәрләр һәм агросәнәгать комплексы өчен башка массакүләм һөнәр кадрлары әзерләүне һәм аларның квалификацияләрен күтәрүне оештырырга;

- хайваннар авыруларын, шулай ук районга хайваннар һәм үсемлекләр авырулары таратучыларны, корткычлар, чүп-үләннәре һәм башка карантин объектлары керүне кисәтү буенча ветеринария һәм фитосанитария хезмәтләре белән үзара булышып эшләргә;

- тракторларның, үзйөрешле юл-төзелеше һәм башка машиналарның, аларга тагылма техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеген координацияләүне тормышка ашырырга;

- районның агросәнәгать комплексын үстерүгә бүленә торган бюджет акчаларының максатчан файдалануына, компетенция кысаларында, контроль булдырырга;

- районда шәхси ярдәмче хуҗалыкларны арттыруга булышлык итәргә;

- крестьян-фермерлык хуҗалыкларына эшчәнлекләрендә, шул исәптән 2018 елда грант алучыларга 2019 елга булган йөкләмәләре нигезендә проектларын тормышка ашырып тәмамлауда методик ярдәм күрсәтергә;

- авыл хуҗалыгы җирләрен файдаланмауга чик кую буенча чаралар күрергә;

- үсемлекчелек продукциясен җитештерүне 5% арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм чаралар күререгә;

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү кооперативлары оештыру мөмкинлекләре, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү кооперативларына ярдәм итү буенча дәүләт программалары, дәүләт ярдәме чаралары кысаларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларга чыгымнарның бер өлешен каплау төрләре һәм тәртибе турында район халкына аңлатуны оештырырга.

**12. Теләче муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башлыкларына 2019 елга түбәндәге бурычлар билгеләргә:**

- үзарасалым җыю максатын халыкка аңлату буенча чараларны, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып, башка муниципаль берәмлекләрнең уңай үрнәкләрен яктыртып, арттырырга кирәк;

- салым салу базасын зурайту максатыннан авыл җирлекләрендә урнашкан хуҗасыз яки хисапка алынмаган милекне теркәү процедурасында инициатива күрсәтергә;

- авыл җирлекләре трриторияләрендә гаилә фермалары булдыруга шартлар тудырырга һәм булышлык итәргә;

- гражданнарның мөрәҗәгатьләре һәм шикаятьләре белән эшләүгә аерым әһәмият бирергә, чөнки аларның көндәлек проблемаларына вакытында җавап бирү җирлек территориясендә яшәүче гражданнар арасында киеренкелек тудыру мөмкинлеген киметә;

- ирекле ягын сүндерү формированиеләренә булышлык итүне дәвам итәргә;

- авыл җирлекләре территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле халык дружиналарының нәтиҗәле эшләвен оештырырга;

- вазифаи затлар тарафыннан коррупциягә каршы законнарны үтәүне тәэмин итәргә;

- авыл җирлекләре территорияләрендә файдалы казылмаларны законсыз чыгаруга юл куймау буенча чаралар күрергә.

**13. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне муниципаль район Советының даими комитетларына һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.**

Теләче муниципаль
районы башлыгы И. Ф. Зарипов